Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

15 ноябрь 2018 ел №126

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге №116 "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында" гы карарга үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" гы 2003 елның 6 октябрендагы №131-ФЗ Федераль Законның 14 нче маддәсе, Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше, 31 бүлеге, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы 29 нче маддәсе нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге №116 "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында" гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 2 октябендәге №141, 2014 елның 19 ноябрендәге №151, 2015 елның 6 маендагы №179, 2015 елның 20 ноябрендәге №13, 2016 елның 8 ноябрендәге №49, 2018 елның 31 маендагы №122 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге 12 абзац белән тулыландырырга:

– "шәһәр бакчалары, парклар, скверлар урнаштыру өчен билгеләнгән җир участокларына карата "0,01 процент";

– 12 абзацны билгеле тәртиптә 13 дип санарга.

2. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылган көннән гамәлгә керә һәм 2018 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының бюджет-финанс сораулары буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хәмидуллин Ф.Р.).

Шәһәр башлыгы А.Р. Хәйруллин